ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Новая, д.52, с. Старое Чурилино,
Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле
авылы, Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

# КАРАР

**14 декабрь 2023 ел** **№ 26**

**Арча муниципаль районы
«Иске Чүриле авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегендә
гражданнардан үзара салым
акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Иске Чүриле авыл җирлеге Советының 2022 елның 04 августындагы 49 номерлы карары нигезендә, җыеннарда кабул ителгән 15.11 2023 № 1, 15.11. 2023 № 2, 16.11 2023 № 3, 22.11.2023 № 4, 22.11. 2023 № 5, 22.11.2023 № 6, 24.11. 2023 № 7 карарларны гамәлгә ашыру максатында, Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Арча муниципаль районы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Арча районы, Иске Чүриле авылы, Новая урамы, 52 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Венета авылы, Школьная урамы, 3 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Ашабаш авылы, Комсомольская урамы, 4а йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Штерә авылы, Советская урамы, 30б йорт.

3. «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара

салым акчаларын җыю тәртибе турында» Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 23 декабрендәге 23 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Иске Чүриле авыл җирлеге
башлыгы урынбасары И.Н. Габдрахманов

Иске Чүриле авыл җирлеге
башкарма комитетының
14.12.2023 ел, № 26
карарына 1 нче кушымта

**Арча муниципаль районы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип (алга таба –Тәртип) Арча муниципаль районы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү Арча муниципаль районы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан, аларның җыеннарда катнашуына һәм тавыш бирүдә белдергән мөнәсәбәтләренә карамастан, 2024 елның 24 февраленә кадәр түләнелә.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары (бергә яшәүче ата-аналары, ир /хатын, балигъ булган балалар).

4. Гражданнарның аерым категорияләре өчен:

а) көндезге уку формасында укучы студентлар,

б) 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнар,

в) хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар,

түләү күләме җирле җыеннар карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

5. Нигезле сәбәпләр булганда, гражданнарга гариза нигезендә түләүне өч айдан да артык булмаган срокка кичектерү бирелә:

а) гаилә әгъзасының үлеме (ата-анасы, хатыны/ире, балалары),

б) янгын яки башка табигый бәла-казалар нәтиҗәсендә зыян күрү.

6. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәр (хәбәрнамә) бланкы гражданнарга мәгълүматны бастырып чыгару (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итү һәм гражданнарның күпләп җыелу урыннарындагы мәгълүмат стендларында, шулай ук почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән җиткерелә.

Хәбәрдә (хәбәрнамәдә) гражданнарның үзара салым акчаларын кертү өчен түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

7. Гражданнарның үзара салымыннан җыелган акчалар Арча муниципаль районы «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына күчерелә.

8. Гражданнарның түләүләре физик затлар кушуы буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия оешмалар аша, почта күчерүе (исәп-хисап оешмалары) яисә Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша

https://uslugi.tatarstan.ru сылтамасы буенча акча күчерү юлы белән башкарыла.

9. Түләү фактын касса кереме ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар раслый.

10. Гражданнарның билгеләнгән срокка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Иске Чүриле авыл җирлеге
башкарма комитетының
14.12.2023 ел, № 26
карарына 2 нче кушымта

## ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № _______

«Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләү турында

Түләүченеен Ф.И.А.и ______________________________

Адресы:____________________________________________________________

______________________________________________________________нигезендә

Сезгә ________________________________ вакытка кадәр

__________________________________________ сум күләмендә чараларны гамәлгә ашыруга бер тапкыр түләнелә торган түләү түләргә кирәк.

Түбәндәге реквизитлар буенча:_________________________________________________

БИК банк ______________________________

Сч. № ___________________________________________

Счетны алучы № _________________________________

ИНН _______________________________________________

КПП _______________________________________________

КБК __________________ОКАТО__________________

Түләүнең билгеләнеше

_____________________________________________________________________________

Житәкче ___________________ ____________________________________________

(имза) ( имзаның аңлатмасы)

М. у.

Кисү сызыгы- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

## ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № _______

«Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына ___________ сум күләмендә үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләү турында

Түләүченеең Ф.И.А.и ________________________________________________________

Адресы: ______________________________________________________________

Алдым "___" ______________________ ел_______________________________

(түләүченең имзасы/ ф.и.а.и.)

*Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, Иске Чүриле авыл җирлегенең башкарма комитетында корешок тутырыла һәм калдырыла.*